СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№16-42 от «11» апреля 2025 г.

2025 һәм 2026 елларда Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. 2025 һәм 2026 елларда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелми дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләп куелганда әлеге карарның 1 пункты кулланылмый.

3. Муниципаль хезмәтнең ачыклыгы һәм аннан бертигез файдалану принципларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү, җирле үзидарә органнарының кадрлар составын формалаштырганда профессиональ кадрларны эзләү һәм аларны җәлеп итү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының оештыру эшләре бүлегенең муниципаль хезмәт һәм кадрлар секторына муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

000040

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (С.М. Сергеев).

Мамадыш
муниципаль районы
Башлыгы В.И. Никитин